ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.04.2023 Олы Кайбыч ав. № 156

Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2023 елның 22 маенда 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында Олы Кайбыч авыл җирлеге, Олы Кайбыч авылы, Үзәк ур., 49А - «Кибет» адресы буенча, шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) урнашкан, кадастр номеры 16:21:010106:199, гомуми мәйданы 1246 кв.м. булган җир кишәрлеген бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проектындагы материаллар белән эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 нче йорт, 2 нче кат адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасында танышырга мөмкин.

Җир кишәрлеген файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 нче йорт, 2 нче кат адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасын билгеләргә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына:

җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар һәм материаллар уздыру турында

мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында, массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлгән «Кайбыч таңнары» («Кайбицкие зори») челтәрле басмасында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров